**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 9 февралендәге 384 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 29 гыйнварындагы 225 номерлы**
**«Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына**
**милек ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча**
**эшче төркем төзү турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркемнән аның аерым әгъзалары чыгу белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 гыйнварындагы 225 номерлы «Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем төзү турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 июлендәге 2284 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 297 номерлы, 2023 елның 28 мартындагы 899 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем составыннан Р.Р.Шәфигуллинны, Ф.Р.Мортазинаны, Ф.В.Нурмөхәммәтовны, С.А.Мироновны, Ә.Ф.Идиятуллинны чыгарырга;

1.2. Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә: эшче төркем сәркатибе сыйфатында – Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты икътисади үсеш комитетының эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы Л.И.Кашапованы; эшче төркем әгъзалары сыйфатында – Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы Р.Х.Шәмсетдиновны; Казан

шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы В.В.Жаворонковны; Казан шәһәре Башкарма комитеты Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисенең беренче урынбасары вазифаларын башкаручы – милек казнасы бүлеге башлыгы А.Ф.Газизовны.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**